**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге составына керүче Тогаево авылында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

**КАРАР**

21 ноябрь, 2020 ел № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә 2019 елның 21 нче, ноябрендә узган гражданнар җыеннары нәтиҗәләре белән түбәндәге мәсьәлә буенча гражданнар җыены беркетмәсе төзелде:

«2021 елда яшәү урыны буенча Шилнәбаш авыл җирлеге Тогаево авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз илле)сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә:

- юлларны асфальт валчык белән каплап алу һәм чистарту, юлларны чокырлы-чакырлы ремонтлау»;

ӘЙЕ ЮК».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 39 кеше кертелде, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны – 38 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча җыенда катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

«Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 38 кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенында катнашучы 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәр нигезендә гражданнар җыены карар бирде:

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Тогаево авылында гражданнар җыенын узган, гражданнар җыены нәтиҗәләрен гамәлдә дип танырга.

2. «2021 елда яшәү урыны буенча Тогаево авыл җирлеге Шилнәбаш авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә 1000 (бер мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I, II төркем инвалидлары һәм Бөек Ватан сугышы ветераннары, ялгыз яшәүче өлкән яшьтәге гражданнар һәм көндезге формада укучы студентлар, күп балалы гаиләләр өчен бер тапкыр түләү күләмен киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз илле)сум күләмендә билгеләргә, әлеге сумманы түбәндәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерергә; »

-юлларны асфальт валчык белән каплап алу һәм чистарту, юлларны чокырлы-чакырлы ремонтлау;

3. Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Тогаево авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырып, халыкка җиткерергә.

4. Тукай муниципаль районы Шилнәбаш авыл җирлеге Тогаево авылы гражданнар җыены нәтиҗәсен Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Шилнәбаш авыл җирлеге Башлыгы О.А. Гончарова